ГЛАВА
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.04.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 01-109**

Зеленодольск муниципаль районы медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе турында

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Зеленодольск муниципаль районы медальләрен булдыру турында Зеленодольск муниципаль районы Советы карарларын гамәлгә ашыру максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе нигезләмәсен әлеге карарның 1 нче кушымтасында каралганча расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе составын әлеге карарның 2 нче кушымтасында каралганча расларга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 28 апрелендәге 01-109 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы медальләрен бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районы медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе (алга таба - комиссия) Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Зеленодольск муниципаль районы медальләрен булдыру турында Зеленодольск муниципаль районы Советы карарларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.2. Үз эшчәнлегендә комиссия Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, бүләкләү мәсьәләләрен регламентлаштыручы Зеленодольск муниципаль районы карарларына , Зеленодольск муниципаль районы медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе хакындагы әлеге нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) таяна.

## II. Комиссия функцияләре

2.1. Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Советы карарлары белән расланган медальләр турындагы нигезләмәләр нигезендә алынган үтенечнамәләрне һәм үтенечнамәләргә кушымта итеп бирелгән материалларны карый.

2.2. Комиссия тапшырылган документлар нигезендә бүләкләүгә тәкъдим ителүчеләрнең казанышларын бәяли һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

күрсәтелгән бүләккә тәкъдим итәргә;

бүләкләү төрен үзгәртеп бүләкләүгә тәкъдим итәргә;

бүләкләүне кире кагарга.

## III. Комиссияне төзү тәртибе, составы һәм аның эшен оештыру

3.1. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләреннән, Зеленодольск муниципаль районының оешма һәм учреждение җитәкчеләреннән, иижтимагый советыннан һәм иҗтимагый оешмалардан төзелә. Комиссиянең сан составы - 9 кеше.

3.2. Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия әгъзалары һәм комиссия секретаре керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссиянең персональ составы һәм андагы үзгәрешләр Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

3.3.
Комиссия кергән һәм үтенечнамәләргә кушып бирелә торган материалларны Зеленодольск муниципаль районы Советы карарлары белән расланган медальләр турындагы нигезләмәләр нигезендә карый һәм әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган карарларның берсен әлеге документлар комиссиягә кергән көннән алып биш көн эчендә кабул итә.

3.4. Комиссия кирәк булган саен җыела, ләкин елына бер тапкырдан да сирәгрәк түгел. Утырышны комиссия рәисе, ә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары үткәрә. Кирәк булганда комиссиянең чираттан тыш утырышы уздырыла.

3.5. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. "Риза" һәм "каршы" дип бирелгән тавышлар саны тигез булганда, Рәиснең тавышы хәлиткеч була. Комиссия утырышы көндез яки читтән торып уздырыла.

3.6. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

3.7. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм документлар белән тәэмин итүне комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

3.8. Комиссия комиссия секретаре тарафыннан бүләкләү турында үтенечнамә кире кагылган очракта, 7 эш көне эчендә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, тәкъдим итүче якка хат проекты әзерләнә.

## IV. Комиссия әгъзаларының хокуклары:

4.1. Комиссия әгъзалары өч көннән дә соңга калмыйча комиссия утырышына чыгарыла торган материаллар белән танышалар.

4.2. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

фикер алышына торган мәсьәлә буенча үз фикерен әйтергә һәм дәлилләргә, үз тәкъдимнәрен һәм рекомендацияләрен кертергә;

фикер алышына торган мәсьәлә буенча өстәмә белешмә-мәгълүмат материалы тапшырырга;

бүләкләү документларын рәсмиләштерү буенча методик ярдәм күрсәтергә.

## V. Комиссия әгъзаларының бурычлары

Комиссия әгъзаларының бурычлары:

комиссия утырышында булырга һәм мәсьәләләр буенча фикер алышуда актив катнашырга; утырышны сәбәпсез калдырмаска;

комиссия әгъзалары функцияләрен үтәүгә бәйле рәвештә үзләренә бирелгән хезмәт мәгълүматын саклап калырга;

бүләкләү материалларының копияләрен ясарга юл куймаска;

танышу өчен алынган документларның копияләрен комиссия утырышыннан соң комиссия секретарена кайтарырга.

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 28 апрелендәге 01-109 номерлы карарына
2 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Афанасьев<br>Михаил Павлович | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,<br>**комиссия рәисе** |
| 2. | Кадникова<br>Эльза Ренат кызы | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары<br>**комиссия рәисе урынбасары** |
| 3. | Данилова<br>Резеда Юсып кызы | «Зеленодольск муниципаль районы музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры,<br>**комиссия секретаре** |
| 4. | Хәбибуллин<br>Зөлфәт Флүн улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, **комиссия әгъзасы** |
| 5. | Купоросова<br>Ольга Владимировна | Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы рәисе, **комиссия әгъзасы** (килешү буенча) |
| 6. | Калистратова<br>Веста Владимировна | Зеленодольск муниципаль районында «Беренчеләр хәрәкәте» Бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең җирле бүлекчәсе җитәкчесе, **комиссия әгъзасы** (килешү буенча) |
| 7. | Гыйззәтуллин<br>Тәлгать Рифкат улы | Зеленодольск муниципаль районы сугыш һәм хезмәт ветераннарының (пенсионерларының), Кораллы көчләрнең һәм хокук саклау органнарының иҗтимагый оешмасы советы рәисе, **комиссия әгъзасы** (килешү буенча) |
| 8. | Копвиллем<br>Наилә Нургаяз кызы | Гомумроссия мәгариф профсоюзының Зеленодольск территориаль оешмасы рәисе, комиссия әгъзасы (килешү буенча) |
| 9. | Никифоров<br>Вера Николаевна | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең оештыру - методика эше буенча баш табиб урынбасары, к**омиссия әгъзасы** (килешү буенча) |